ДҮШӘМБЕ
8 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 81 (5881)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

КОЛХОЗ СТРОЕН ҮСТЕРҮ ИНТЕРЕСЛАРЫНДА

Бүген „Правда“ да ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм ССР Союзы Халык Комиссарлары Советының „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турындагы карары игълан ителә. Бу карарның гаять зур принципиаль әһәмияте бар. Сүз, хәзерләүләрнең һәм сатып алуларның хәзерге системасына аерым төзәтмәләр кертү турында бармый, бәлки авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында тамырдан үзгәрешләр турында, хәзерләүләрнең яңа принциплары турында бара.

Моңа үткән елның июлендә үк нигез салынган иде. ССР Союзының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының „Колхозларда җәмагать терлекчелеген үстерү чаралары турында“гы карары белән мәҗбүри рәвештә ит тапшыруны терлекләр санына карап исәпләү тәртибе бетерелгән иде. Мәҗбүри рәвештә ит тапшыруларны колхозга беркетелгән мәйданның һәрбер гектарыннан исәпләү тәртибе кертелгә иде.

Шул чагында ук инде һәрбер колхозда булырга тиеш булган мөгезле эре терлекләрнең, дуңгызларның, сарыкларның һәм кәҗәләрнең мәҗбүри минимум саны билгеләнгән иде. Терлекләр санының бу минимумы да шулай ук колхоз җиренең гомуми күләменнән чыгып исәпләнә.

Бер елдан ким вакыт эчендә колхозларда җәмагать терлекчелеге бик нык алга атлады. Колхозларда күп меңнәрчә яңа терлекчелек фермалары оештырылды, ә җәмагать терлекләренең саны күп йөз меңнәрчә артты. Шулай итеп ит хәзерләүнең яңа системасы тормышта тикшерелде. Шушы тәҗрибәдән чыгып, шушы елның башында колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшырулары буенча да шундый ук тәртип, ягни бу тапшыруларны сарыклар санына карап исәпләмичә, колхозга беркетелгән җир мәйданының һәрбер гектарыннан исәпләү тәртибе кертелде.

Хәзер партия Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары белән, хәзерге контрактация договорлары системасы буенча тапшырылачак күп кенә техник культуралардан (мамыктан, шикәр чөгендереннән, җитеннән, киндердән, тәмәкедән һәм башкалардан) һәм бакчачылыктан кала барлык авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу өчен шундый ук тәртип билгеләнде.

Һәрбер колхозның авыл хуҗалыгы продукциясен, колхоз файдалануында булган җир күләменә карап, дәүләткә гектар исәбеннән тапшыруы хәзерләүләр политикасының җитәкче принципы булып әверелә. Бу, барлык колхозлар ел саен дәүләткә җир мәйданының (сөрү җиренең, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнең) һәрбер гектарына билгеләнгән норма буенча маглүм күләмдә, терлекчелек продукциясе: ит, сөт, йон, брынза, күн чималы, йомырка тапшырырга тиешләр дигән сүз.

Барлык колхозлар ел саен дәүләткә маглүм күләмдә бөртекле ашлыкны һәм майлы культураларны, яшелчәләрне, бәрәңгене, печәнне, үлән орлыкларын мәҗбүри тапшыруларның һәм сатып алуларның әлегә кадәр яшәп килгән системасы буенча, ягни бу культуралар чәчүлекләренең гектарыннан исәпләү системасы тапшырмыйча сөрү җиренең һәр гектарыннан билгеләнгән нормалар буенча тапшырырга тиешләр.

Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында бу үзгәрешләр нәрсәдән килеп чыкканнар? Алар, хәзерләүләрнең һәм сатып алуларның үз заманында яхшы роль уйнаган, әлегә кадәр яшәп килгән тәртибенең хәзер искергән булуыннан һәм колхозның җәмагать хуҗалыгын тагын да үстерүгә тоткарлык ясавыннан килеп чыкканнар.

Итне, сөтне, йонны мәҗбүри рәвештә тапшыруны колхозда булган терлекләр санына карап билгеләү терлекчелекне үстерүче алдынгы колхозларны уңайсыз хәлгә куя иде. Колхозның терлеге никадәр күп булса, колхозда терлекләр саны никадәр күбрәк артса, ул дәүләткә терлекчелек продукциясен шул кадәр күбрәк бирә иде. Һәм киресенчә, терлекчелек белән шөгыльләнмәгән, колхоз фермалары булмаган, фермаларда терлекләр санын арттырмаган, артта калган колхозлар күп уңайлырак шартларда булып чыгалар иде, чөнки алар дәүләткә терлекчелек продуктларын кимрәк бирәләр иде, яисә аеруча артта калганнар аларны бөтенләй бирмиләр иде.

Кырчылыкта да шуның шикеллерәк хәл туа иде. Кырчылык продукциясен чәчүлекләр буенча мәҗбүри рәвештә тапшыру алдынгы колхозларның бөртекле һәм техник культуралар чәчүлекләре белән күмелүләренә, ә артта калган колхозлар өчен чәчү планнарының киметелүенә китерә иде. Куаклыкларны чистартуга, сазламыкларны киптерүгә, сөрелми яткан җирләрне сөрүгә, ягни чәчүлекләрне киңәйтү өчен, колхозларның җәмагать җирләреннән иң дөрес һәм иң нәтиҗәле итеп файдалану өчен мөмкинлек бирә торган бөтен нәрсәләргә тоткарлык ясала иде.

Эш шул кадәргә барып җитә иде, кайбер артта калган колхозларның булдыксыз җитәкчеләре алдынгы артельләрнең председательләреннән, аларның һәрбер гектар җирдән иң күп нәтиҗәле итеп файдаланырга омтылуларыннан көләләр иде. Алар: „Сез нәрсәгә тырышасыз инде, үзегезгә мәшәкать кенә арттырасыз. Бездә эш бөтенләй башкача: сыерлар юк, сарыклар юк, дуңгызлар юк һәм без чөгендер дә чәчмибез. Чәчтең, урып-җыйдың—һәм бөтен эш бетте“ диләр иде.

Хәзер бу гаделсезлеккә чик куела. Артта калган колхозның җитәкчесе алдынгы артель председателе артыннан бик тырышып барырга, анардан хуҗалыкны дөрес алып бару осталыгына өйрәнергә тиеш булачак. Әгәр дә ул моны эшләмәсә, ул вакыт колхозчылар мондый председательдән, мондый правлениедән баш тартачаклар, аның урынына күп эшлеклерәк хуҗаны сайлаячаклар. Эш шулай булачак, чөнки колхоз продукциясен дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшыруда гектар исәбеннән тапшырудан гыйбарәт булган бердәнбер дөрес принцип билгеләнде.

Хәзерләүләрнең яңа тәртибе барлык колхозларның һәм колхозчыларның интересларын, бөтен ил интересларын саклый, алдынгы колхозларның инициативасына ярдәм итә. Һич шиксез, колхозлар үзләре өчен билгеләнгән терлекләр минимумы белән генә тукталып калмаслар, бәлки аны тагын да арттырырлар. Терлекчелек продукциясен мәҗбүри рәвештә тапшыруны үтәгәннән соң мондый колхозларның үз йоннары, үз тиреләре, димәк үз аяк киемнәре, үз толыплары, үз сбруйлары булачак.

Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә ат тапшыруларын билгеләү халык хуҗалыгы һәм ил оборонасы өчен аеруча әһәмиятле. Хәзер бездә ат асраучылык күтәреләчәк. Аның белән әлегә кадәр булган кебек аерым алдынгы хуҗалыклар, атчылык сөючеләр генә түгел, бәлки барлык колхозлар да җидди рәвештә шөгыльләнәчәк. Барлык колхозлар хуҗалыкка да, оборона өчен дә яраклы булган ат үстерергә тиешләр

Партия Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары колхозларның һәм колхозчыларның инициативасын чишеп җибәрә, аларның колхоз производствосының барлык тармакларын барлык чаралар белән киңәйтүгә булган кызыксынуларын арттыра. Хәзер инде һәрбер колхозчы һәм колхозчы хатын-кыз үз колхозының дәүләт каршындагы йөкләмәләрен бер елга гына түгел, бәлки берничә елга алдан белеп торачак. Алар үзләренең җитәкчеләреннән хуҗалыкны оста итеп, акыл белән алып баруны, җирнең һәрбер гектарыннан күбрәк продукция һәм күбрәк доход алуны, артель байлыгын арттыруны таләп итәчәкләр.

Орлыкны тегермәндә тарттырган өчен натуралата күрәк оны түләүне бетерү колхозда тегермән эшен тизрәк аякка бастыруга һәм үстерүгә, җирле хуҗалыкның бу таркау тармагында тәртип урнаштыруга ярдәм итәчәк. Хәзерләү аппаратларын берләштерү, хәзерләүчеләр санын киметү, үзәкләштерелмәгән хәзерләүләр буенча өлкәдән тыш хәзерләүчеләрне урыннан алу һәм бу хәзерләүләрне җирле оешмаларга тапшыру авыл хуҗалыгы продуктлары сатып алуда бу оешмаларның ролен һәм җаваплылыгын күтәрә. Җирле халыкның үз өлкәсендә, үз районында җитештерелгән яшелчәгә, бәрәңгегә, терлекчелек продуктларына соравын канәгатьләндерү мөмкинлекләре күп тапкырлар артачак.

Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр урыннардагы партия һәм совет органнары алдына җидди бурычлар куялар. Алар үзләрен яңача күрсәтергә, торган саен күбрәк дәрәҗәдә колхоз производствосын оештыручылар ролендә чыгарга тиешләр. Хәзер алардан авыл хуҗалыгы техникасын, колхозларның экономикасын, һәрбер колхозның үзенчәлекләрен тирәнтен белү элеккегә караганда да күбрәк таләп ителә. Бары тик шул хәлдә генә аларның җитәкчелеге колхозчыларга артель хуҗалыгын һәр яклап юлга салуда булышлык итүче, югары квалификацияле булып әверелер.

Колхозчылар массасының киң инициативасына таянып, аларның гаять бай производство тәҗрибәсеннән һәм инициативасыннан файдаланып, партия һәм хөкүмәт карарларын үтәү өчен большевикларча көрәшеп, партия һәм совет җитәкчеләре колхозларның җәмагать хуҗалыгын тагын да көчле күтәрүне тәэмин итәрләр.

„Правда“ның 7 нче апрель номерыннан кыскартылып алынды.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКТЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ САТЫП АЛУ ПОЛИТИКАСЫНДА ҮЗГӘРЕШЛӘР

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карары

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы, авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләүдә һәм сатып алуда хәзерге тәртипнең искергәнлеген, колхозларның җәмагать хуҗалыгын тагын да үстерүгә һәм ныгытуга тоткарлык ясавын күрсәтеп үтәләр.

СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының „Колхозларда җәмагать терлекчелеген үстерү чаралары турында“ 1939 нчы елның 8 нче июлендә һәм „Дәүләткә мәҗбүри рәвештә йон тапшыру турында“ 1940 нчы елның 31 нче январенда чыгарылган карарлары белән колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит һәм йон тапшырулары системасындагы гаять зур җитешсезлекләр бетерелделәр. Бу җитешсезлекләр шуннан гыйбарәт иде: алдынгы колхозлар уңайсыз хәлгә куелалар иде, аларның җәмагать терлекчелеген үстерү белән кызыксынулары югала иде һәм, киресенчә, терлекчелек фермалары булмаган яки фермаларында терлекләр санын арттырмаучы, артта калган колхозлар льготалы хәлдә булып чыгалар иде. Бу җитешсезлекләр хәзергә әле колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә сөт тапшыруларында яшәп киләләр.

Хәзерләүләрнең бу системасының кимчелеге шунда ки, колхозларның мәҗбүри рәвештә ит, йон һәм сөт тапшырулары колхозларда булган җәмагать терлекләренең санына карап билгеләнә. Бу хәл җәмагать терлекчелеген үстергән һәм аны елдан-ел арттыра баручы колхозларның дәүләткә мәҗбүри тапшырулар буенча торган саен күбрәк күләмдә ит, сөт һәм йон тапшырырга тиеш булуларына, ә терлекчелек фермаларын начар үстергән колхозларның дәүләткә мәҗбүри тапшырулар буенча продуктларны аз бирүләренә, терлекчелек фермалары бөтенләй булмаган һәм аларны оештырырга теләмәгән колхозларның исә льготалы хәлдә булып чыгуларына китерә, чөнки алар дәүләткә мәҗбүри тапшырулар буенча терлекчелек продуктларын тапшырмыйлар.

Колхозларның ит, йон һәм сөт тапшыруларын гектар исәбеннән исәпләүгә күчү хәзерләүләр системасында югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерүне тәэмин итеп кенә калмый, бәлки җәмагать терлекчелеген үстерү эшен алга алып баручы куәтле күтәргеч тә булып тора.

Бу әйтелеп үткән җитешсезлекләр терлекчелек продуктларының тире һәм йомырка кебекләрен хәзерләү эшендә дә бар. Бөтен күн чималын дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшыру колхозларның терлекчелекне үстерү белән кызыксынуларын өзә һәм дәүләткә иң күп санда күн чималы тапшыручы алдынгы колхозларны үз кирәкләре өчен үзләрендә кирәк кадәр күн-тире булдыру мөмкинлегеннән мәхрүм итә, аларны җәмагать терлекчелеген үстермәүче һәм дәүләткә күн чималы тапшырмаучы колхозлар белән бер тигез хәлгә куя.

Йомырка хәзерләүнең дөрес булмаган системасы, колхозларда кошчылык фермаларын киңәйтү өчен гаять зур мөмкинлекләр булуга да карамастан, һәм кошчылык инкубатор станцияләренең киң челтәре булуга да карамастан, колхозларның зур күпчелегендә җәмагать кошчылыгы булмауның төп сәбәпләреннән берсе булып тора.

Сыйфат ягыннан иң яхшы атлары булган колхозларның дәүләткә оборона кирәкләре өчен барлык иң яхшы атларны бирүләре, ә югары сыйфатлы атлары булмаган колхозларның бөтенләй ат тапшырмаулары тәртибе колхозларны атларның сыйфатын яхшырту белән кызыксынудан мәхрүм итә һәм атларны яхшыртуда уңышлары булган колхозларны уңайсыз хәлгә куеп, шуның белән бергә, ат асраучылыкны үстерүгә начар караучы колхозларны узындыра.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә ашлык, дөге, көнбагыш һәм бәрәңге тапшыру буенча хәзерге исәпләү тәртибенең төп җитешсезлеге шуннан гыйбарәт ки, тапшыруның күләмнәре шул культуралар буенча булган чәчү планына карап билгеләнә, бу исә налог көчендә булган мәҗбүри тапшыруларны исәпләү өчен ныклы база бирми, колхозларның ашлык, көнбагыш һәм бәрәңге чәчүлекләре планнарын киметергә омтылуларына китерә, бу культураларның чәчү мәйданнарын киметүгә юл куя, эшләнми яткан җирләрне сөрү, сазламыкларны киптерү һәм куакларны арчу юлы белән яңа җирләр үзләштерү өчен кызыксыну тудырмый.

Элекке вакытта дәүләтнең ашлык байлыгында зур урын тоткан күрәк оны хәзер инде үзенең элекке әһәмиятен югалтты, үзенең гомерен үткәрде һәм колхоз тегермәннәренең үсүенә тоткарлык булып, бар кадәр тегермәннәргә булышлык итүдә, яңа тегермәннәр төзүдә колхозларның кызыксынуларын бетерә һәм колхозчылар өчен өстәмә кыенлыклар тудыра.

Яшелчә, майлы орлыклар, үлән орлыклары, шулай ук печән кебек продуктларны дәүләт өчен хәзерләү средствосы булган контрактация, хәзерләүләрнең үзенә аерым методы булу ягыннан үзенең әһәмиятен югалтты, колхозларда бу югарыда күрсәтелгән авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүне җитәрлек үстерүне тәэмин итми.

Дәүләт өчен ит, яшелчә һәм башка шуның кебек продуктларны сатып алуны һәм үзәкләштерелмәгән төстә хәзерләүне үткәрүче хәзерләү органнарының оешу структурасында зур җитешсезлекләр бар. Бу җитешсезлекләр, барыннан да элек, хәзерләү органнарының күп санлы булуларыннан гыйбарәт, алар товар җитештерү районнарында тулып яталар, дәүләт өчен хәзерләү һәм сатып алу эшенә комачаулыйлар, моның дәүләт өчен артык расходлар китереп чыгаруын инде әйтеп тә торасы юк.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы карар бирәләр:

1. Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә ашлык, дөге, көнбагыш һәм бәрәңге тапшыруларын исәпләүнең хәзерге тәртибен —бу культураларның чәчүлекләре планына карап исәпләү тәртибен һәм яшелчәләргә, майлы культуралар орлыкларына, үлән орлыкларына, шулай ук печәнгә контрактация ясау системасын бетерергә.

2. 1940 нчы елгы иген уңышыннан башлап колхозларны дәүләткә мәҗбүри рәвештә ашлык, дөге, бәрәңге, яшелчә (кәбестә, аш чөгендере, кишер, суган, кыяр һәм помидор), майлы культура (көнбагыш, кудряш җитен, клещевина, соя, горчица, рапс, кунжут) орлыклары һәм үлән (люцерна, клевер, тимофеевка, житняк, эспарцет һәм вика) орлыклары тапшыруга колхозларга беркетелгән сөрү җирләренең һәрбер гектары исәбеннән тартырга дип билгеләргә.

Югарыда әйтелгән культураларны мәҗбүри рәвештә тапшыруларны исәпләгәндә сөрү җирләре исәбенә түбәндәгеләр керәләр: түтәл бакчалары, шулай ук сөрелми яткан җирләрне сөрү, сазламыкларны киптерү һәм куаклыкларны арчу юлы белән дәүләт планы буенча үзләштерелергә тиеш булган җирләр (үзләштерүнең икенче елында). Мамык, шикәр чөгендере, җитен, киндер, цикорий, тәмәке, махорка, эфир-май сүсле яңа культуралар, дару үләннәре, кольза, сафлор, кориандр, анис, мәк, рыжик, арахис, ляллеманций, перилла, каучуклы культуралар, тут, фрукта, җиләк, виноград культуралары һәм субтропик культуралар чәчелгән җирләр югарыда күрсәтелгән культураларны тапшыруны исәпләү җирләре исәбенә кермиләр, бу культураларның продукциясе дәүләткә хәзерге тәртиптә тапшырыла.

3. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле культуралар һәм дөге тапшыру нормаларын СССР да бөртекле ашлык тапшыруның гомуми күләмен 925 миллион потка кадәр җиткерергә кирәклектән чыгып билгеләргә.

Көнбагыш, майлы культуралар, бәрәңге һәм үлән орлыклары тапшыру нормаларын бу культураларны тапшыру һәм аларга контрактация ясау планыннан чыгып, ә яшелчәләргә карата өлкә (край, республика) һәм район өчен 1939 нчы елны расланган контрактация планыннан һәм үзәкләштерелмәгән сатып алулар планыннан чыгып билгеләргә.

Крайларга, өлкәләргә һәм республикаларга, аерым районнар һәм колхозлар өчен, гомумән край, өлкә һәм республика буенча булган гомуми тапшыру саннарыннан читкә чыкмыйча, яшелчә тапшыру планыннан килеп чыга торган нормаларны киметү яки арттыру, ә кайбер районнарны һәм колхозларны яшелчә тапшырудан бөтенләй азат итү һәм 1939 нчы елны контрактация һәм үзәкләштерелмәгән сатып алулар буенча яшелчә тапшырмаган районнарны һәм колхозларны яшелчә тапшыруга тарту хокукын бирергә.

Хабаровск һәм Приморье крайларында, Чита һәм Ленинград өлкәләрендә, Азербайҗан, Үзбәкстан, Төркмәнстан һәм Таҗикстан ССР ларда хәзерге нормалар киметелгән булганлыктан һәм алар яшелчәгә булган, үсеп бара торган сорауны тәэмин итмәгәнлектән, тимер юл буйлап бәрәңгене өлкәләр арасында күчереп йөртүне бетерүне тәэмин итмәгәнлектән бәрәңге һәм яшелчә тапшыру нормаларын беркадәр күтәренке итеп билгеләргә.

Яшелчә культураларының берсен икенче культура белән алмаштыруга СССР Совнаркомы раслаган эквивалент буенча рөхсәт итәргә.

4. 1940 нчы елдан башлап дәүләткә мәҗбүри рәвештә печән тапшыруны кертергә, тапшыру нормасын сөрү мәйданына карап (2 нче пунктка туры китереп), шулай ук болыннар мәйданына карап билгеләргә, шуның белән бергә, сөрү җиреннән һәм болыннардан, су басмый торган һәм су баса торган җирләрдән тапшыру нормаларын төрлечә билгеләргә.

Тимер юлдан һәм су юлларыннан ерак урнашкан колхозларга печән урнына, билгеләнгән эквивалент буенча, бөртекле ашлык, ит, сөт продукциясе һәм йон тапшырырга рөхсәт итәргә.

5. Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә сөт тапшыруларын сыерлар саны исәбеннән исәпли торган хәзерге тәртипне һәм брынза хәзерләүнең хәзерге тәртибен бетереп, 1941 нче елдан башлап, колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә брынза тапшырулары тәртибен кертергә, колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә сөт һәм брынза тапшыруларын колхозларга беркетелгән җир мәйданының (сөрү җиренең, шул исәптән бакчаларның һәм түтәл бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнең) һәр гектарыннан исәпләүне билгеләргә.

Үзләре өчен билгеләнгән минимумнан артык сыерлары булган колхозларга, 1941 нче елдан башлап, сөт тапшыру буенча үзләренең дәүләт каршындагы йөкләмәләрен үтәгәннән соң, дәүләткә сөт тапшыру буенча колхозчыларның йөкләмәләрен үтәү өчен колхозчылар өчен сөт тапшырырга һәм шулай итеп колхозчыларны сөтнең беркадәр өлешен яки бөтенләен тапшыру йөкләмәләреннән азат итәргә рөхсәт итәргә.

6. Күн чималы һәм йомырка хәзерләү буенча хәзерге тәртипне бетерергә һәм колхозларның, колхоз йортларының һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә 1940 нчы елдан башлап күн чималы һәм 1941 нче елдан башлап йомырка тапшыруларын колхозлар өчен җир мәйданының (сөрү җиренең, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнең) һәр гектарыннан исәпләнә торган нормалар буенча билгеләргә.

Йомырка тапшыру буенча үзләренең йөкләмәләрен үтәгәннән соң, дәүләткә йомырка тапшыру буенча колхозчыларның йөкләмәләрен үтәү тәртибендә колхозчылар өчен йомырка тапшырырга һәм шулай итеп, колхозчыларны йомырка тапшыру йөкләмәләреннән беркадәр яки бөтенләй азат итәргә колхозларга рөхсәт итәргә.

7. Колхозларга беркетелгән җир мәйданына (сөрү җиренә, шул исәптән җимеш һәм түтәл бакчаларына, болыннарга һәм көтүлекләргә карап) армия өчен яраклы булган югары сыйфатлы атлар үрчетү һәм үстерү буенча барлык колхозлар өчен мәҗбүри минимум билгеләргә. 1941 нче елдан башлап билгеләнгән минимум атлар санына туры китерелгән нормалар буенча оборона кирәкләре өчен мәҗбүри рәвештә ат тапшыру тәртибен кертергә.

8. Ит сатып алуны планлаштыруның хәзерге тәртибен бетерергә һәм дәүләт өчен ит сатып алу планы тулысынча республика, өлкә, край, район һәм колхоз өчен, дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит тапшыру күләмнәренә пропорциональ рәвештә, СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты раслаган еллык нормалар буенча колхозларның җир мәйданнары күләменә карап исәпләнә дип билгеләргә. Сатып алу буенча дәүләт планыннан тыш сатып алынган барлык нәрсәләрне урындагы тәэмин өчен республикалар, крайлар һәм өлкәләр карамагында калдырырга, өлкәдән тыш барлык үзәкләштерелмәгән хәзерләүчеләрне хәзерләү эшеннән алырга.

9. Дәүләткә күн чималы сатып алуны аны сатучыларга күн товарлар сату тәртибендә үткәрергә, мәҗбүри рәвештә күн чималы һәм ит тапшыруны үтәгән һәм терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планының үтәлүен тәэмин иткән колхозларга күн чималын, үзләре белгәнчә файдалану өчен, дәүләт һәм кооператив предприятиеләренә эшкәртүгә бирергә рөхсәт итәргә.

10. Дәүләт өчен яшелчә һәм бәрәңге сатып алуны, хәзерләүләрне мәҗбүри рәвештә тапшыру буенча үткәрүче төп хәзерләүчеләр аркылы үткәрергә, урыннардагы хәзерләүчеләрне калдырып, өлкәләрдән тыш үзәкләштерелмәгән хәзерләүчеләрне яшелчә, бәрәңге һәм фрукта хәзерләү базарларыннан алырга.

Өлкәләрдән тыш үзәкләштерелмәгән хәзерләүчеләрнең аппаратын һәм техник базасын, яшелчәләрне үзәкләштерелгән тәртиптә хәзерләүне көчәйтү өчен, Наркомторг карамагына бирергә.

11. Наркомлегпромның „Союззаготкож“ аппаратын, Наркомтекстильнең „Союззаготшерсть“ аппаратын һәм Наркомвнешторгның (җәнлек һәм каракүл совхозларыннан тыш) „Главпушнина“ аппаратын Наркомзаг составында күн чималлы, йон, җәнлек тиресе һәм мех хәзерләү буенча дәүләтнең бер хәзерләү оешмасына берләштерергә.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы авыл хуҗалыгы продуктларының барлык төрләре буенча хәзерләүчеләр санын, бигрәк тә үзәкләштерелмәгән хәзерләүләр буенча эшләүчеләр санын тагын да киметергә кирәк дип саныйлар.

12. 1940 нчы елның 1 нче июленнән башлап барлык дәүләт, кооператив һәм колхоз тегермәннәрендә, ярма яргычларда һәм май заводларында бөртекле культураларны, кузаклыларны, ярмаларны, дөгене һәм майлы культураларны эшкәрткән өчен натуралата күрәк оны алуны бетерергә һәм бу культураларны эшкәрткән өчен акчалата түләү билгеләргә.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре И. СТАЛИН.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе В. МОЛОТОВ.

СССР-НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ТАРАФЫННАН КАБУЛ ИТЕЛГӘН ЗАКОННАР

Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турында закон

Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы хезмәт ияләренең теләген үтәү йөзеннән һәм милләтләрнең иреклe үсеше принципын кулланып, Совет Социалистик Республикалар Союзының Верховный Советы карар бирә:

1. 1940 нчы елның 12 нче мартында СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры нигезендә Финляндиядән СССР га күчә торган территорияне, турыдан-туры Ленинградка караган кечерәк полосадан башкасын, Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы составына тапшырырга, шул исәптән Выборг, Антреа, Кексгольм, Сортавала, Суоярви, Куолаярви шәһәрләрен тапшырырга.

2. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзергә.

3. Шушы законның беренче пункты буенча Карелия составына кушыла торган территориядә урнашкан промышленность предприятиеләрен, бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган аз гына сандагы предприятиеләрдән башкаларын, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы карамагына тапшырырга.

4. Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советыннан һәм Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы Верховный Советыннан РСФСР белән Карел-Фин ССР арасында төгәл чикне билгеләү проектын СССР Верховный Советы карамагына кертүләрен сорарга.

5. СССР Конституциясенең (Төп Законының) 34 һәм 35 нче статьяләренә туры китереп, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасыннан СССР Верховный Советына депутатлар сайлау үткәрергә.

6. СССР Верховный Советы Президиумына бу сайлауларның көнен билгеләүне тапшырырга.

7. Шушы законга туры китереп, СССР Конституциясенең (Төп Законының) 13 нче статьясенә өстәмә кертеп, аны түбәндәгечә язарга:

„13 Статья. Совет Социалистик Республикалар Союзы тигез хокуклы Совет Социалистик республикаларның:

Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының,

Украина Совет Социалистик Республикасының,

Белоруссия Совет Социалистик Республикасының,

Азербәйҗан Совет Социалистик Республикасының,

Грузия Совет Социалистик Республикасының,

Әрмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Төркмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасының,

Таҗикстан Совет Социалистик Республикасының,

Казагстан Совет Социалистик Республикасының,

Кыргызстан Совет Социалистик Республикасының,

Карел-Фин Совет Социалистик Республикасының ихтиярлы берләшүләре нигезендә төзелгән Союз дәүләте".

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 31 март, 1940 ел.

Совет Социалистик Республикалар Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турында закон

Совет Социалистик Республикалар Союзының Верховный Советы карар бирә:

1. СССР нын СССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан кертелгән 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын Союз Советының һәм Милләтләр Советының Бюджет Комиссияләре докладлары буенча кабул ителгән үзгәртүләр белән, ягъни доходлар буенча барлыгы—183.954.633 мең сум һәм расходлар буенча барлыгы—179.913.376 мең сум итеп, Союз бюджеты средстволары 1941 нче елның 1 нче январена СССР Дәүләт Банкысындагы счетларда 1.475.000 мең сум калдык итеп һәм шуның өстенә доходларның расходлардан 2.566.257 мең сумга артык итеп расларга.

2. Шушы законның беренче статьясенә туры китереп, Союз бюджетының доходларын һәм расходларын доходлар буенча 141.094.905 мең сум һәм расходлар буенча 137.053.648 мең сум итеп, 1941 нче елның 1 нче январена СССР нын Дәүләт Банкысындагы счетларда 1.475.000 мең сум средстволар калдык итеп һәм шуның өстенә доходларның расходларга караганда 2.566.257 мең сум артык итеп расларга.

3 нче Союзный республикаларның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетларын түбәндәге сумаларда расларга:

	Доходлар буенча (мең сумнарда)	Расходлар буенча (мең сумнарда)
Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы	25.244.171	25.244.171
Шулардан: республика бюджеты	15.019.725	6.463.988
жирле бюджетлар	10.224.446	18.780.183
Украина Совет Социалистик Республикасы	8.096.411	8.096.411
Шулардан: республика бюджеты	5.382.427	2.259.018
жирле бюджетлар	2.713.984	5.837.393
Белоруссия Совет Социалистик Республикасы	2.144.597	2.144.597
Шулардан: республика бюджеты	1.673.177	716.789
жирле бюджетлар	471.420	1.427.808
Азербайжан Совет Социалистик Республикасы	1.040.721	1.040.721
Шулардан: республика бюджеты	837.596	391.110
жирле бюджетлар	203.125	649.611
Грузия Совет Социалистик Республикасы	1.227.451	1.227.451
Шулардан: республика бюджеты	983.707	494.502
жирле бюджетлар	243.744	732.949
Әрмәнстан Совет Социалистик Республикасы	469.664	469.664
Шулардан: республика бюджеты	401.976	212.509
жирле бюджетлар	67.688	257.155
Төркмәнстан Совет Социалистик Республикасы	526.552	526.552
Шулардан: республика бюджеты	459.704	238.327
жирле бюджетлар	66.848	288.225
Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасы	1.486.969	1.486.969
Шулардан: республика бюджеты	1.210.812	558.907
жирле бюджетлар	276.157	928.062
Таҗикстан Совет Социалистик Республикасы	527.105	527.105
Шулардан: республика бюджеты	470.613	230.354
жирле бюджетлар	56.492	296.751
Казагстан Совет Социалистик Республикасы	1.660.650	1.660.650
Шулардан: республика бюджеты	1.436.660	628.831
жирле бюджетлар	223.990	1.031.819
Кыргызстан Совет Социалистик Республикасы	435.437	435.437
Шулардан: республика бюджеты	389.929	173.852
жирле бюджетлар	45.508	261.585
Союзный республикаларның дәүләт бюджетлары буенча барлыгы	42.859.728	42.859.728
Шулардан: республика бюджетлары	28.266.326	12.368.187
жирле бюджетлар	14.593.402	30.491.541

4. Республика бюджетларыннан АССР ларның бюджетларына һәм жирле Советларның бюджетларына чигерүләрне түбәндәге сумаларда расларга:

	(Мең сумнарда)
Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы	8.555.737
Украина Совет Социалистик Республикасы	3.123.409
Белоруссия Совет Социалистик Республикасы	956.388
Азербәйҗан Совет Социалистик Республикасы	446.486
Грузия Совет Социалистик Республикасы	489.205
Әрмәнстан Совет Социалистик Республикасы	189.467
Төркмәнстан Совет Социалистик Республикасы	221.377
Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасы	651.905
Таҗикстан Совет Социалистик Республикасы	240.259
Казагстан Совет Социалистик Республикасы	807.829
Кыргызстан Совет Социалистик Республикасы	216.077
Барлыгы	15.898.139

5. СССР Совнаркомының резервлар фонды исәбеннән кирәкле булган средстволарны бүлеп, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасының 1940 нчы елгы бюджетын өстәмә рәвештә карауны һәм раслауны СССР Халык Комиссарлары Советына тапшырырга.

6. Гомуми Союз дәүләт налогларыннан республика һәм жирле бюджетларга чигерүләрне 1940 нчы елга түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

а) шәһәрләрдә торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә алына торган җыемнан РСФСР, Украина ССР, Белоруссия ССР, Азербәйҗан ССР, Грузия ССР, Әрмәнстан ССР һәм Үзбәкстан ССР бюджетларына—50 процент һәм Төркмәнстан ССР, Таҗикстан ССР, Казагстан ССР һәм Кыргызстан ССР бюджетларына—100 процент,

б) авыл җирләрендә торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә алына торган җыемнан барлык союзный республикаларның бюджетларына—100 процент;

в) колхозлардан доход налогы буенча һәм колхозчылардан һәм ялгыз хуҗалыкчылардан авыл хуҗалыгы налогы буенча керемнәрдән—РСФСР, Украина ССР, Белоруссия ССР бюджетларына — 75 процент һәм Азербәйҗан ССР, Грузия ССР, Әрмәнстан ССР, Төркмәнстан ССР, Үзбәкстан ССР, Таҗикстан ССР, Казагстан ССР һәм Кыргызстан ССР бюджетларына 100 процент;

г) эшчеләр һәм хезмәткәрләр арасында һәм шәһәрнең башка халкы арасында урнаштырылган дәүләт заемы сумасыннан,—союзный республикалар бюджетына 50 процент, алардан җирле бюджетларга җибәрү өчен 25 процент; колхозчылар һәм ялгыз хуҗалыкчылар арасында урнаштырылган заем сумасыннан,—җирле бюджетларга җибәрү өчен союзный республикалар бюджетларына 90 процент;

д) машина-трактор станцияләре доходларыннан союзный республикалар бюджетларына—50 процент, алардан җирле бюджетларга җибәрү өчен 30 процентка кадәр.

7. ССР Союзы Халык Комиссарлары Советына,—оборот налогыннан союзный республикаларга чигерүләрнең СССР Верховный Советы раслаган сумаларына туры китереп, һәр союзный республика буенча шушы налогтан чигерүләр процентларын билгеләүне тапшырырга.

8. СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының доходлар буенча 127.480.890 мең сум күләмендә һәм расходлар буенча 124.038.942 мең сум күләмендә, доходларның расходларга караганда 3.441.948 мең сум артык итеп үтәлүе турындагы отчетны расларга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 3 апрель, 1940 ел.

Халыктан доход налогы турында закон

I. Гомуми положениеләр

Статья 1. Доход налогы эшчеләргә, хезмәткәрләргә, әдәбият һәм сәнгат работникларына, кустарьларга, һөнәрчеләргә һәм СССР территориясендә аерым доход чыганаклары булган башка гражданнарга салына.

Статья 2. Налог салынудан түбәндәгеләр азат ителәләр:

а) Советлар Союзы Геройлары, СССР орденнары белән яки почетлы революцион корал белән бүләкләнгән гражданнар һәм хезмәт геройлары—ала торган хезмәт хаклары буенча.

Башка чыганак доходлары буенча бу гражданнар, әгәр доходлары елына 6.000 сумнан артмаса, налогтан азат ителәләр, ә доходлары елына 6.000 сумнан артык булса, салына торган доход сумасыннан 6.000 сум чигерелә:

б) хәрби хезмәткәрләр һәм военнобязанныйлар—Эшче-Крестьян Кызыл Армиясендә, Эшче-Крестьян Хәрби Диңгез Флотында, НКВД ның чик буе һәм эчке гаскәрләрендә ала торган акча довольствиеләре буенча;

в) аена хезмәт хаклары 150 сумнан артмый торган эшчеләр һәм хезмәткәрләр;

г) алтын һәм платина промышленносте старательләре, кургашын һәм башка төрле кирәк металлар чыгару һәм эшкәртү предприятиеләренең старательләре—старательлек эшләрендә ала торган хезмәт хаклары буенча;

д) стипендияләре аена 210 сумнан артмаган стипендия алучы укучылар—шушы стипендия буенча;

е) доходлары елына 600 сумнан артмый торган кооперативлаштырылмаган кустарьлар һәм һөнәрчеләр, корылма хуҗалары һәм башка гражданнар;

ж) пенсионерлар—ала торган пенцияләре буенча;

Статья 3. СССР Финанс Халык Комиссариатына һәм союзный республикаларның финанс халык комиссариатларына аерым түләүчеләр өчен һәм түләүчеләр группалары өчен налог буенча өстәмә льготалар билгеләү хокукы бирелә.

Автономияле республикаларның финанс халык комиссариатларына, край һәм өлкә финанс бүлекләренә аерым түләүчеләр өчен льготалар билгеләү хокукы бирелә.

Статья 4. Авыл хуҗалыгы налогы салынырга тиешле доходларга доход налогы салынмый.

II. Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакларына налог салу тәртибе

Статья 5. Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән налог ай саен аларның үткән айдагы хезмәт хаклары буенча түбәндәге күләмнәрдә алына:

Айлык хезмәт хакы күләме	Айлык налог сумасы
151 сумнан 200 сумга кадәр	1 с. 20 т. һәм 150 сумнан арткан сумадан 3%
201 „ 300 „ „	2 с. 70 т. „ 200 „ „ „ 3,3%
301 „ 500 „ „	6 с. 00 т. „ 300 „ „ „ 4%
501 „ 700 „ „	14 с. 00 т. „ 500 „ „ „ 5%
701 „ 1.000 „ „	24 с. 00 т. „ 700 „ „ „ 6%
1.001 „ һәм артыграк „	42 с. 00 т. „ 1.000 „ „ „ 7%

Статья 6. Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең налог салына торган айлык хезмәт хаклары составына аларның үткән айда алган хезмәт хакларының бөтен сумасы кертелә, мәсәлән: төп хезмәт хакы, эш вактыннан тыш һәм эш башыннан эшләү өчен түләүләр, персональ өстәмә түләүләр, хезмәткә премия түләве булганда түләнә торган премияләр, файдаланылмаган отпуск өчен компенсация һәм башкалар.

Статья 7. Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең налог салына торган айлык хезмәт хаклары составына налог исәплләгәндә түбәндәгеләр кертелми:

а) эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә аеруча казанышлары һәм хезмәтләре өчен администрациянең приказы буенча бер тапкыр түләнә торган премияләр һәм бүләкләр.

б) хезмәт турындагы гамәлдәге законнар нигезендә командировка расходларын каплауга һәм башка урыннарга эшкә җибәргәндә түләнә торган сумалар;

в) авыл җирләрендә һәм эшчеләр поселкыларында торучы медицина, ветеринария һәм зоотехника работникларына һәм мәгариф эше работникларына түләүсез квартира бирү урнына түләнә торган сумалар;

г) эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына керми торган һәр төрле натураль түләүләр, шулай ук бу түләүләр урнына бирелә торган акча сумалары;

д) вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособиеләр, урыннан чыгарылганда бирелә торган пособиеләр һ. б

е) эшчеләрг һәм хезмәткәрләргә үз инструментларының амортизациясе өчен түләнә торган сумалар.

Статья 8. Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең бер үк вакытта (төп эшләре урнында булмаганда) һәм вакытлы эшләрне үтәүдән алган хезмәт хакларыннан налог һәрбер эш урны буенча аерым рәвештә исәпләнә. Бу хезмәт хаклары өчен налог салынмый торган минимум (2 нче статья) кулланылмый һәм аена 150 сумга кадәр булган хезмәт хакыннан налог айлык хезмәт хакы сумасының 0,8 проценты күләмендә исәпләнә.

Статья 9. Тәрбияләрендә 3 кешедән артык кеше булган эшчеләр һәм хезмәткәрләр өчен төп эшләре урнында налог күләме 30 процентка киметелә.

Югарыда күрсәтелгән льгота тәрбиядә торучы кешеләрнең саны турында йорт идарәсенең яки хезмәт ияләре депутатлары авыл советы башкарма комитетының белешмәсе нигезендә бирелә. Белешмәләр ел саен китерелә.

Статья 10. Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән налогны предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар исәплиләр һәм ай саен айның икенче яртысы өчен булган хезмәт хакыннан тотыла.

Союзный һәм автономияле республикаларның финанс халык комиссариатларына, край һәм өлкә финанс бүлекләренә аерым хәлләрдә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның үтенүләре буенча налогны алдагы ай хезмәт хакыннан тотып калырга рөхсәт бирү хокукы бирелә.

Статья 11. Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар хезмәт хакы бирүгә банк учреждениесеннән сума алу белән бер үк вакытта эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән тотылырга тиеш булган налог сумасын бюджет исәбенә күчерәләр.

Банк учреждениеләрендә расчет счетлары булмаган оешмалар эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән тотылган налог сумаларын тотканның икенче көнендә банк учреждениесенә кертәләр.

Статья 12. Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән налог тоту турында СССР Финанс Халык Комиссариаты билгеләгән форма буенча һәм срокларда район (шәһәр) финанс бүлекләренә квартал саен отчет бирергә тиешләр.

Статья 13. Түбәндәгеләргә налог эшчеләр һәм хезмәткәрләр белән бер тигез нигезләрдә салына:

а) аена 210 сумнан артык стипендия алучы укучылар, шулай ук аспирантлар;

б) адвокатлар—юридик консультацияләрдә эшләүләре өчен ала торган хаклары буенча.

Статья 14. Түбәндәгеләргә налог эшчеләр һәм хезмәткәрләр белән бер тигез нигезләрдә, ләкин налог күләмен 10 процентка артыграк итеп салына:

а) артельләрнең гомуми мастерскойларында эшләүче кооперативлаштырылган кустарьлар һәм һөнәрчеләр;

б) кооперативлаштырылган кустарьлар һәм һөнәрчеләр, шулай ук эшчеләр һәм хезмәткәрләр—үз өйләрендә эшләгән өчен артельләрдән һәм предприятиеләрдән ала торган хезмәт хаклары буенча, әгәр алар эшне аерым гражданнар өчен үтәмәсәләр, промыслода үз материалларын кулланмасалар, һәм үз эшләрендә махсус җиһазлар (тегү машиналарыннан башка машиналар, станоклар һ. б.) кулланмасалар;

в) транспорт промысло-кооператив артельләренең членнары (эш терлекләре җәмагатьләштерелгән булса).

Статья 15. Түбәндәгеләргә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакларына билгеләнгән ставкалар буенча налог салына:

а) авторлык таныклыклары алынган уйлап табулары өчен акча алучы гражданнар, шулай ук техника һәм оештыру уңайлыклары өчен акча алучы гражданнар;

б) хәзерләүчеләргә җәнлек тиресе һәм мех чималы тапшыручы гражданнар, хәзерләүчеләргә чимал тапшырудан булган хезмәт хакы буенча.

III. Әдәбият һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларына налог салу тәртибе

Статья 16. Әдәбият һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларыннан (шул исәптән артистларның даими эшләү урыннарыннан тыш булган хезмәт хакларыннан) налог һәрбер хезмәт хакы түләү урныннан һәм түбәндәге күләмнәрдә алына:

Еллык хезмәт хакы	Налог сумасы
1.800 сумга кадәр	Хезмәт хакы сумасыннан 0,8%
1.801 сумнан 2.400 сумга кадәр	14 с. 40 т. һәм 1.800 сумнан арткан сумадан 3%
2.401 „ 3.600 „ „	32 с. 40 т. „ 2.400 „ „ „ 3,3%
3.601 „ 6.000 „ „	72 с. 00 т. „ 3.600 „ „ „ 4%
6.001 „ 8.400 „ „	168 с. 00 т. „ 6.000 „ „ „ 5%
8.401 „ 12.000 „ „	288 с. 00 т. „ 8.400 „ „ „ 6%
12.001 „ 20.000 „ „	504 с. 00 т. „ 12.000 „ „ „ 7%
20.001 „ 30.000 „ „	1.064 с. 00 т. „ 20.000 „ „ 8%
30,001 „ 50.000 „ „	1.864 с. 00 т. „ 30.000 „ „ „ 10%
50.001 „ 70.000 „ „	3.864 с. 00 т. „ 50.000 „ „ „ 12%
70.001 „ 100.000 „ „	6.264 с. 00 т. „ 70.000 „ „ „ 17%
100.001 „ 150 000 „ „	11.364 с. 00 т. „ 100.000 „ „ „ 25%
150.001 „ 200.000 „ „	23.864 с. 00 т. „ 150.000 „ „ „ 35%
200.001 „ 300.000 „ „	41.364 с. 00 т. „ 200.000 „ „ „ 45%
300.001 сум һәм артыграк „	86.364 с. 00 т. „ 300.000 „ „ „ 50%

Статья 17. Әдәбият һәм сәнгат работникларына налог предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан исәпләнә һәм хезмәт хакы түләгәндә тотып калына. Һәрбер түләү вактында шул елда ясалган түләүнең гомуми сумасы буенча налогка перерасчет ясала.

Әдәбият һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларына налог салган вакытта икенче статьяда билгеләнгәнчә налог салынмый торган минимум кулланылмый.

IV. Кооперативлаштырылмаган кустарь-ремесло промыслоларыннан, корылышлардан, шәһәрләрдәге авыл хуҗалыгыннан һәм ялланмыйча эшләнә торган башка эшләрдән килгән доходларга налог салу тәртибе

Статья 18. Кооперативлаштырылмаган кустарь-ремесло промыслоларыннан, корылышлардан, шәһәрләрдәге һәм эшчеләр поселкыларындагы авыл хуҗалыгыннан алынган доходлардан һәм 5, 13, 14, 15, 16 һәм 22 статьяләр тәртибендә налог салынган доходлардан тыш башка доходлардан налог түбәндәгә күләмнәрдә алына:

Еллык доходның күләме	Налогның сумасы
1.200 сумга кадәр	Доход сумасыннан 4%
1.201 сумнан 1.800 сумга кадәр	48 сум һәм 1.200 сумнан арткан сумадан 6%
1.801 „ 2.400 „ „	84 „ „ 1.800 „ „ „ 10%
2.401 „ 3.600 „ „	144 „ „ 2.400 „ „ „ 14%
3.601 „ 4.800 „ „	312 „ „ 3.600 „ „ „ 18%
4.801 „ 6.000 „ „	528 „ „ 4.800 „ „ „ 23%
6.001 „ 8.400 „ „	804 „ „ 6.000 „ „ „ 30%
8.401 „ 12.000 „ „	1.524 „ „ 8.400 „ „ „ 38%
12.001 „ 18.000 „ „	2.892 „ „ 12.000 „ „ „ 46%
18.001 „ 24.000 „ „	5.652 „ „ 18.000 „ „ „ 55%
24.001 „ һәм югары	8.952 „ „ 24.000 „ „ „ 60%

(Дәвамы 3 нче биттә).

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясе

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ТАРАФЫННАН КАБУЛ ИТЕЛГӘН ЗАКОННАР

Халыктан доход налогы турында закон

(Дәвамы)

Статья 19. Үз материалыннан әйберләр эшләп чыгаручы кооперативлашмаган кустарьларга, шулай ук үз атлары, үгезләре, дөяләре һ. б. белән эшләүче извозчикларга налог салганда, налог күләме 35 процентка, ә дини культларның хезмәтчеләренә һәм хезмәт итеп табылмаган доходлары булган башка кешеләргә—40 процентка арта.

Статья 20. Кооперативлаштырылмаган кустарьлар белән һәм һөнәрчеләр белән бер үк нигезләрдә, ләкин налог күләмен 35 процентка арттырмыйча, түбәндәгеләргә налог салына:

а) кооперативлаштырылган кустарьлар һәм һөнәрчеләр, шулай ук эшчеләр һәм хезмәткәрләр, артельләрдән һәм предприятиеләрдән үзенә өйгә алып эшләгән эшеннән килгән доходлар буенча, әгәр алар артельләрдән һәм предприятиеләрдән тыш аерым гражданнар өчен эшләсәләр, яки промыслода үз материалларын куллансалар, яисә үз эшләрендә махсус җиһазлардан (тегү машиналарыннан башка машиналардан, станоклардан һ. б.) файдалансалар;

б) эш терлекләре җәмагатьләштерелмәгән транспорт промысло-кооператив артельләренең членнары.

Статья 21. Шәһәрләрдә һәм эшчеләр поселкыларында авыл хуҗалыгыннан килгән доходлардан доход налогы алына.

Авыл хуҗалыгыннан налог салына торган доходның күләме күрше районнарда авыл хуҗалыгы налогы салу өчен билгеләнгән доход нормалары буенча билгеләнә.

Авыл хуҗалыгыннан булган налог салына торган доход сумасына авыл хуҗалыгы продуктларын сатудан алынган сума да керә.

Үзләренең ярдәмче авыл хуҗалыклары шул райондагы колхозчылар өчен авыл хуҗалыгы артеле уставы тарафыннан рөхсәт ителгән күләмнәрдән артык булмаган эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең авыл хуҗалыгы продуктларын сатудан алынган сумалары налог салына торган доходлар исәбенә кертелми.

Статья 22. Врачларның, фельдшерларның, адвокатларның, укытучыларның һәм башкаларның частный практикадан алынган хезмәт хакларыннан доход налогы түбәндәге күләмнәрдә алына:

Еллык доходның күләме	Налогның сумасы
1.000 сумга кадәр	Доход сумасыннан 1 %.
1.000 сумнан 2.000 сумга кадәр	10 сум һәм 1.000 сумнан арткан сумадан 1,5 %.
2.000 сумнан 3.000 сумга кадәр	25 „ „ 2.000 сумнан арткан сумадан 3,3 %.
3.000 сумнан 4.000 сумга кадәр	58 „ „ 3.000 сумнан арткан сумадан 3,7 %.
4.000 сумнан 5.000 сумга кадәр	95 „ „ 4.000 сумнан арткан сумадан 4,5 %.
5.000 сумнан 6.000 сумга кадәр	140 „ „ 5.000 сумнан арткан сумадан 7,5 %.
6.000 сумнан 8.000 сумга кадәр	215 „ „ 6.000 сумнан арткан сумадан 13 %.
8.000 сумнан 10.000 сумга кадәр	475 „ „ 8.000 сумнан арткан сумадан 20 %.
10.000 сумнан 12.000 сумга кадәр	875 „ „ 10.000 сумнан арткан сумадан 25 %.
12.000 сумнан 15.000 сумга кадәр	1375 „ „ 12.000 сумнан арткан сумадан 30 %.
15.000 сумнан 20.000 сумга кадәр	2275 „ „ 15.000 сумнан арткан сумадан 34 %.
20.000 сумнан һәм аннан да югары	3975 „ „ 20.000 сумнан арткан сумадан 38 %.

Статья 23. 5, 13, 14, 15, 16 һәм 22 нче статьялар тәртибендә налогка тартылган гражданнарның доходларыннан башка, налог барлык чыганаклардан алынган гомуми доход буенча исәпләнә.

Налог салына торган доход дип валовой доход белән (акчалата һәм натураль формада) һәм доход алуга бәйле булган расходлар арасындагы аерма хисаплана.

Натураль формада алына торган доходлар (авыл хуҗалыгы продуктлары, ягулык, кустарь әйберләре һ. б.) налог салына торган доходны билгеләгәндә урыннардагы базар бәяләре буенча исәпләнәләр.

Статья 24. Налог салына торган доходларга кермиләр һәм налог салынмый:

а) СССР ның дәүләт заемнары облигацияләре буенча отышлар һәм бу облигацияләр буенча процентлар, шулай ук хөкүмәт тарафыннан рөхсәт ителгән лотереяләр буенча отышлар;

б) дәүләт хезмәт саклык кассаларындагы вкладлар буенча процентлар;

в) шәхси һәм мөлкәт страхованиесе кагыйдәләре нигезендә налог түләүче тарафыннан алынган страхование акчалары;

г) күп балалы аналарга дәүләт пособиеләре;

д) налог түләүченең үзенең әйберләрен сатудан алынган сумалар;

е) мирас һәм бүләк тәртибендә алынган сумалар;

ж) материаль ярдәм тәртибендә алынганнар;

з) алиментлар.

Статья 25. Налог салу 18 һәм 22 нче статьялар тәртибендә налог түләүчеләрнең тору урыннары буенча район (шәһәр) финанс бүлекләре тарафыннан, әгәр промысел башка районда булса—промыселның тору урны буенча үткәрелә.

Статья 26. 18, 19, 20, 21 һәм 22 нче статьяларда күрсәтелгән түләүчеләр налогны түбәндәге тәртиптә түлиләр:

а) үткән ел өчен доходлар буенча исәпләнгән еллык налог окладының һәрбер кварталда 25 әр процентын, ә налог салуга беренче тапкыр гына тартылган түләүчеләр,—шушы ел өчен күздә тотылган доход буенча исәпләнгән окладның 25 процентын кертәләр.

б) ел беткәндә яки доход чыганаклары яшәүдән тукталганда налогның еллык оклады асылда алынган доход буенча исәпләнә, һәм бу окладлар белән налог сумалары арасындагы аерма 15 көн срок эчендә түләттерелә яки түләүчегә кайтарып бирелә.

Статья 27. Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар извозчикларга хезмәт хакы түләгәндә түләнә торган хезмәт хакы сумасының 25 процентын налог исәбенә тотып калалар һәм тотып калынган сумаларны бюджетка кертү өчен һәр декада саен банк учреждениеләренә кертәләр.

Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан тотып калынган сумалар, гомуми билгеләнгән срокларда түләнергә тиеш булган налог сумасын каплау өчен район (шәһәр) финанс бүлекләре тарафыннан алыналар.

Статья 28. Налог түләү өчен түләнергә тиешле срок: 15 нче март, 15 нче май, 15 нче август һәм 15 нче ноябрь.

Статья 29. Үзләренә вактында салынмаган кешеләргә узган ике елдан да артык булмаган чорга налог салына.

Шулай ук дөрес салынмаган налогның да узган ике ел эчендә булганнары гына яңадан каралалар.

V. Налог түләүчеләрне һәм аларның доходларын учетка алу тәртибе

Статья 30. Налог түләүчеләрне учетка алу һәм аларның доходларын билгеләү түбәндәге нигезләрдә үткәрелә:

а) налог түләүчеләр тарафыннан һәр елны 15 нче январьга финанс органнарына бирелә торган декларацияләр;

б) СССР Финанс Халык Комиссариаты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан, шулай ук йортларның управляющийлары һәм корылмаларның хуҗалары тарафыннан финанс органнарына бирелә торган мәгълүматлар;

в) промыселларны һәм занятиеләрне тикшерү материаллары һәм налог түләүчеләрнең доходлары турындагы башка белешмәләр.

Статья 31. Финанс органнарының җитәкче работникларына түбәндәге хокуклар бирелә:

а) налогны исәпләү һәм тотып калу буенча, шулай ук тотылган налог сумаларын бюджетка тапшыру буенча предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның документларын тикшерү;

б) налог салу өчен кирәкле булган белешмәләрне (статья 30) финанс органнарына бирергә тиеш булган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның документларын тикшерү;

в) эш башкарыла торган бинага тоткарлыксыз керү, бу промыселларга һәм занятиеләргә караган документларны тикшерү һәм запас чималны, материалларны һәм әзер әйберләрне карау.

VI. Налог турындагы законны бозган өчен җәза бирү һәм налог түләүчеләрнең җаваплылыгы

Статья 32. Эшчеләрдән, хезмәткәрләрдән, әдәбият һәм сәнгать работникларыннан налог тотмаган өчен, йөк йөртү белән шөгыльләнүче гражданнардан налогның аванс сумаларын тотмаган яки дөрес тотмаган өчен, шулай ук тотылган сумаларны банк учреждениеләренә вактында тапшырмаган өчен предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның баш (өлкән) бухгалтерлары 100 сумнан артык булмаган күләмдә штрафка тартылалар.

Статья 33. Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән налог тоту турындагы отчетларны финанс органнарына вактында бирмәгән өчен, шулай ук башка гражданнарга налог салу өчен кирәк булган мәгълүматларны вактында бирмәгән (яки тулы бирмәгән) өчен, мәгълүматлар һәм отчетлар бирергә җаваплы булган кешеләр 100 сумнан артык булмаган күләмдә штрафка тартылалар.

Дөрес булмаган мәгълүмат бирүче кешеләр уголовный тәртиптә җавапка тартылалар.

Статья 34. Декларацияләрне срогына бирмәгән кешеләр 200 сумнан артык булмаган күләмдә штрафка тартылалар.

Декларацияләрдә дөрес булмаган мәгълүмат бирүче кешеләр уголовный тәртиптә җавапка тартылалар.

Статья 35. Бу законны бозган өчен штраф салу һәм уголовный җавапка тарту турында эш кузгату район (шәһәр) финанс бүлекләре мөдирләренә йөкләтелә.

Статья 36. Налогны билгеләнгән срокларда түләмәгән хәлләрдә недоимщикларга карата түбәндәге җәзалау чаралары кулланыла:

а) түләүне кичектергән өчен узган һәрбер көн өчен 0,2 процент күләмендә пеня алына;

б) налог түләү срогы үтү белән недоимщикның милкенә опись төзелә һәм налог түләмәү турындагы эш халык судына бирелә, налог түләмәүчеләрнең недоимкаларын каплау өчен кирәкле булган күләмдә халык суды карары буенча милекләре сатыла;

в) налогны түләмәү вакыйгалары берничә тапкыр булганда недоимщиклар уголовный җавапка тартылалар.

Статья 37. Заявление һәм жалоба бирү налогны түләттерүне туктатмый.

Налог түләүче файдасына карар чыгарылган хәлләрдә, дөрес алынмаган сумалар һәм алынган милекләре 10 көн срок эчендә кайтарып бирелергә тиеш.

Милке сатылган булганлыктан аны кайтарып бирү мөмкин булмаган хәлләрдә, аны сатудан асылда алынган сумалар күләмендә аның бәясе түләнергә тиеш.

Статья 38. Бу законны гамәлгә куючы инструкция СССР Финанс Халык Комиссариаты тарафыннан чыгарыла.

Статья 39. Бу закон 1940 нчы елның 1 нче январеннан гамәлгә кертелә.

Эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән (һәм алар белән бер дәрәҗәдә булган кешеләрдән) бу закон нигезендә налог беренче тапкыр 1940 нчы елның май аеның икенче яртысы өчен булган хезмәт хакыннан тотыла.

Статья 40. Украина ССР нең Волын, Дрогобыч, Львов, Ровно, Станислав һәм Тарнополь өлкәләрендә һәм Белоруссия ССР ның Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка һәм Пинск өлкәләрендә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең, әдәбият һәм сәнгать работникларының хезмәт хакларыннан, шулай ук врачларның, фельдшерларның, адвокатларның һәм башка кешеләрнең частный практикадан алынган доходларыннан налог шушы закон нигезендә алына.

Бу өлкәләрдә гражданнарның башка чыганаклардан алынган доходлары буенча налог, СССР Совнаркомының 1940 нчы ел 19 нчы мартта чыгарган 370 нче номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә алына.

Статья 41. Бу законны гамәлгә кертү белән түбәндәгеләрне көчләреннән югалткан дип санарга:

а) „Алтынның платина промышленносте турында, алтынның һәм платинаның саклау һәм аларның әйләнеше турында" СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының 1929 нчы ел, 8 нче май карарының 15 нче статьясен (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1929 ел, № 33, ст. 292; 1930 ел, № 41, ст. 426; 1932 ел, № 59, ст. 349);

б) СССР ның ерак урыннарында эш һәм шәһәрләрдән тыш булган урыннарда эшләүче кешеләргә налог турында СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының 1930 нчы ел, 12 нче август карарының 28 нче статьясен (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1930 ел, № 41, ст. 427);

в) уйлап табулар һәм техник яхшыртулар турында 1931 нче елның 9 нчы апрелендә СССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы тарафыннан расланган положениенең 94 нче статьясен (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1931 ел, № 21, ст. 181);

г) налоглар һәм налог булмаган җыемнарны түләттерү турында 1932 нче елның 17 нче сентябрендә СССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы белән расланган Положениенең 12 нче статьясен (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1932 ел, № 69, ст. 410—6);

д) хосусый кешеләрдән доход налогы алу турындагы положение, 1934 нче ел, 17 нче май (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1934 ел, № 27, ст. 211—6; 1935 ел, № 4, ст. 30; 1936 ел, № 1, ст. 4 һәм № 2, ст. 18 һәм 1937 ел, № 18, ст. 64 һәм № 19, ст. 72);

е) эшчеләр, инженерлар, техниклар, хезмәткәрләр һәм обобществленный промышленностеның махсус-ревизия заводларында хезмәт күрсәтүче кече персонал өчен торак һәм культура-көнкүреш төзелеше ихтыяҗлары өчен алынучы налог хакында Положение раслау турында СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1934 нче ел, 13 нче июльдәге 1646—690 нчы номерлы карарының 2 нче статьясен;

ж) „Эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә түләнә торган премияләрне доход налогыннан, торак һәм культура-көнкүреш төзелеше ихтыяҗлары җыемыннан азат итү турында" СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 14 нче апрель карарын (СССР ның Законнар Җыентыгы, 1935 ел, № 22, ст. 170).

Статья 42. Союзный республикаларның халык комиссарлары Советларына бу закон нигезендә килеп чыга торган үзгәрешләрне республикаларның законнарына кертергә тәкъдим итәргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль, 4 апрель 1940 ел.

Язгы чәчү кампаниясенә товарлар. РӘСЕМДӘ: Татсоюзның культбазасы работникларыннан Воробьев һәм Сәйдәшев иптәшләр районнарга җибәрү өчен товар сайлыйлар. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БУЕНЧА ЭШЧЕ-АВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ РЕЙДЕ

РЕЙД ЭШТӘ ХӘРӘКӘТ ТУДЫРДЫ

АПАС. (Телефон буенча). Апас районында эшче-авыл хәбәрчеләре рейде буенча оештырылган бригадалар колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү эшләрен киң җәелдереп җибәрделәр.

Рейд бригадалары кайбер колхозларда чәчүгә хәзерлек эшләрендә күп кенә җитешсезлекләрне ачалар.

Мәсәлән, „Кызыл таң" колхозында рейд бригадасы язгы чәчүгә хәзерлек эшләрендә тынычлану настроениесе булуны фаш итте. Колхоз председателе Шәйхи иптәш Гаязов:

— Безнең барлык әйберләр дә хәзер инде,—дисә дә, рейд бригадасы тикшергәннән соң, күп кенә сабаннар, тырмалар һәм чәчү машиналарының бөтенләйгә ремонтланмаганлыгы беленде. 1 чәчү машинасы рейд бригадасы эшли башлагач боз астыннан казып алынды һәм ремонтка бирелде. Иптәш Баһавиев җитәкчелек итә торган 4 нче бригадада сабаннар һәм пастромка баулары атларга яраксыз итеп эшләнгәннәр. Бригада аларны яңадан ясарга кирәклеген күрсәтте.

„Кызыл таң" колхозында эш атларын тәрбияләү бөтенләй канәгатьләнерлек түгел. Эш атларының 40 тан артыгы түбән көрлектә, 15 баш ат бөтенләй ябык. Сабанга яки тырмада йөрергә дә яраксызлар. Атлар вактында тиешле ялга куелмаган һәм аларга нормаль рәвештә фураж бирелми. Ат караучы Шакир иптәш Гайнеттинов бу эштә үзен бөтенләй җавапсыз саный. Атларны чистартмый.

Ат караучылар чәчү вактында кайсы атның нинди эштә булачагын да белмиләр. Рейд бригадасы бу җитешсезлекләрне бетерү буенча тиешле чаралар күрде. Кайсы атның нинди эштә файдаланылачагын һәм аның белән кем эшләргә тиешлеге ат караучыларга аңлатылды һәм ул турыда аңлатма язып ат абзарларына эленеп куелды.

Колхоз председателе иптәш Гаязов һәм бригадирлардан Дәминев, Шакиров, Баһавиев һәм Салахов иптәшләр әле атларны тәрбияләүгә тиешенчә игтибар бирмиләр. Шуның нәтиҗәсендә 18 баш буаз биядән бары берсе колынлаган, 3 бия колынлау алдында тора, ә калганнары барсы да колын салганнар. Бу турыда тиешле акт язылмаган һәм бу җинаятьле эш өчен бер генә кеше дә җавапка тартылмаган.

Рейд бригадасы кайбер культуралар буенча чәчү орлыкларының җитешмәвен ачты. Бу мәсьәләне колхоз правлениесе һәм башлангыч партоешма каршына куеп, чәчү орлыкларын җиткерү буенча тиешле чаралар күрелде.

Колхозда берничә айдан бирле стена газеталары чыгарылмаган. Рейд бригадасы эшкә башлау белән икенче көнне үк газеталары чыгарылды, ачылган җитешсезлекләр, аларны бетерү юллары язылды, колхоз эшләре буенча газеталарда күп кенә рәсемнәр ясалды. Хәзер барлык бригадаларда стена газеталары чыга башлады. Колхозчылар стена газеталарын, бигрәк тә рәсемнәре күп булганнарын бик яратып, кызыксынып укыйлар һәм аның турында сөйлиләр.

Рейд бригадасы членнары
Хәсәнев, Садреттинов, Галиуллин, Низамова, И. Рәхми.

Берсе яхшы, икенчесе начар

Мамадыш колхозларының язгы чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү буенча хәбәрче бригадалары актив рәвештә эшлиләр. Тикшерү нәтиҗәсендә „Беренче Май" колхозының язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнгән булуы беленде. Бу колхоз язгы чәчүне кыска срокта, уңышлы итеп тәгәлләүне планлаштырган. Иртә культураларны чәчү эше 6 көндә төгәлләргә билгеләнгән. Башаклы культураларның 60 проценты яровойлаштырылган орлыклар белән чәчеләчәк. Уҗымнарның бөтенесе дә тырмаланачак. 10 гектар арыш җирле ашлама сыекчасы белән тукландырылачак. Колхозда атлар көр. Культиваторлар, тырмалар һәм чәчү машиналары барсы да төзек.

Чәчүлек орлыкларның сыйфаты яхшы. Бодай орлыгы коры юл белән агуланган. Солы, тары һәм башка шуның кебек культуралар формалин белән агуланачак. Формалин җитәрлек. Язгы чәчүдә катнашырга тиешле булган колхозчылар барсы да үзләренең нинди эштә, нинди ат һәм кайсы инвентарь белән, шулай ук кайсы участкыда эшләячәкләрен беләләр.

Быел язгы кыр эшләрендә хатын-кызлар аеруча яхшы катнашырга хәзерләнгәннәр. Культиваторда эшләячәк Филиппова һәм Волкова иптәшләр һәр көнне 3 гектар культивацияләргә йөкләмә алганнар. Машина белән чәчүчеләрдән Тараканов һәм Захаров иптәшләр 11 рәтле чәчү машинасы белән һәр көнне кимендә 9 гектар чәчеп барырга йөкләмә алганнар.

„Ленингә истәлек" колхозында исә хәл бөтенләй башкача. Бу колхоз язгы чәчүгә хәзерлек эшендә бик артта калып бара. Колхоз җитәкчеләре орлык туплауны төгәлләгәннәр дә, эш шуның белән тәмам булды дип тынычлап калганнар. Ашламалар хәзерләү, язгы агротехника чараларын үткәрү үз агымына куелган. Кырга тирес чыгару планы бары 31,3 процент, көл җыю планы 39 процент, кош тизәге җыю 15 процент үтәлгән. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт һаман төгәлләнмәгән. Язгы чәчү вактында кырга орлык ташу өчен билгеләнгән арбалар төзек түгел. Колхоз правлениесе атларга бөтенләй әһәмият бирми. Атларны тәрбия итүдә иясезлек, җавапсызлык хөкем сөрә. Шуңар күрә аларның көрлеге дә начар. Тәрбия начар булу нәтиҗәсендә бер ат колын салган.

Колхозчылар арасында политик тәрбия эшләре алып барылмый. Социалистик ярышка җитәкчелек итүче юк. Бу колхозның язгы чәчүгә начар хәзерләнгәнлеге район җир бүлегенә билгеле. Ләкин район җир бүлеге работниклары колхозга булышлык итмиләр.

Ногманов.

Тракторчылар МТС ка кайталар

ЧИСТАЙ, 7 апрель. (Телефон буенча). Чистай МТС ына соңгы көннәрдә генә югары квалификацияле 8 тракторчы кайтты. Бу тракторчылар Чистай МТС ыннан моннан ике-өч ел элек китеп төрле урыннарда эшләгәннәр иде. МТС ка эшкә кайтучылар арасында—Андриянов, Кривошеев, Крылов, Дровин иптәшләр һ. б. Бу иптәшләр үзләре эшләячәк тракторлар белән сезонга 800—1.000 гектарга кадәр эшләү турында йөкләмә алдылар.

К. Исламов.

ЧИРАТТАГЫ ПРИЗЫВКА ҮРНӘК РӘВЕШТӘ ХӘЗЕРЛӘНЕРГӘ

Кызыл Йолдыз районында чираттагы призывка хәзерлек эше көннән-көн киң колач алып бара. Призывка хәзерлек мәсьәләсенә багышлап призывникларның район конференциясе үткәрелде. Конференциядә катнашучылар призывка хәзерлек эшен үрнәк рәвештә оештыру һәм алып бару буенча үзләренә конкрет йөкләмәләр алып, Тәкәнеш районы призывникларын социалистик ярышка чакырдылар.

Призывка һәр яктан үрнәк рәвештә хәзерләнү, дәвалануда мохтаҗ булган, укый-яза белмәүче һәм аз укый-яза белүче призывникларны дәвалау һәм тулы грамоталы итү, призывниклар арасында хәрби һәм политик белемнәрне өйрәнү эшен үрнәк рәвештә оештыру—ярышның төп шартларының кайберләре шулар.

Алынган йөкләмәләрне үтәүдә Яңа Сала авылында оештырылган пунктта өйрәнүче призывниклар яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. Алар сугыш белемнәрен өйрәнү өстендә тырышып эшлиләр, винтовканың һәм противогазның материаль частьләрен өйрәнүне тәмамладылар инде. Хәзер алар Ворошиловча атучы һәм ПВХО значокларына нормалар тапшыралар. Пунктка запастагы кече лейтенант иптәш Мөхәммәтҗанов җитәкчелек итә. Политрук эшен иптәш Шәрәфиев алып бара. Бу иптәшләр үзләренә йөкләнгән эшләрне намус белән башкаралар.

Шуның белән бергә, призывка хәзерлек буенча үзләренә йөкләнгән эш өчен җаваплылыкны сизмәүче кайбер оешмалар һәм җитәкчеләр турында да әйтергә кирәк. Мәсәлән, район сәламәтлек саклау бүлеге (мөдире иптәш Скачков) дәвалануда мохтаҗ булган призывникларны сәламәтләндерү буенча тиешле чаралар күрми, бу эштә җавапсызлык күрсәтә. Мохтаҗ булган призывникларга медицина ярдәме күрсәтү эшенең торышын район сәламәтлек саклау бүлеге бер генә тапкыр да тикшергәне юк.

Район мәгариф бүлеге (мөдире иптәш Измайлов) турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Ул да укый-яза белмәүче призывниклар арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту эшенә тиешенчә әһәмият бирми.

Призывка хәзерлек эшендә булган бу җитешсезлекләр кичекмәстән бетерелергә, ярыш буенча алынган йөкләмәләр тулысынча үтәлергә тиеш.

П. АЛЮКОВ.
Район хәрби комиссарының ярдәмчесе.

ВУЗ ҺӘМ ТЕХНИКУМ ГИМНАСТЛАРЫНЫҢ ШӘҺӘР КҮЛӘМЕНДӘГЕ ЯРЫШЛАРЫ

Физкультура һәм Спорт Эшләре буенча Казан Шәһәр Комитеты 18 һәм 19 нчы апрельдә ВУЗ һәм техникумнардагы гимнастларның шәһәр күләмендәге ярышларын үткәрә. Ярышларда ВУЗ лардан 10 команда, техникумнардан 8 команда катнаша.

Шәһәр Комитетының гимнастика секциясе председателе иптәш Липатов җитәкчелегендә судьялар коллегиясе төзелде.



Казан Елга техникумы быелгы навигациягә яш капитаннардан 98 кеше хәзерләп чыгара. Рәсемдә (сулдан уңга): техникумны тәмамлап чыгучы комсомолецлардан Х. Фәтхуллин, Н. Нигмәтуллина һәм Г. Булатов иптәшләр техникумның пароход модельләре кабинетында.
В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Навигация алдыннан

СТАХАНОВЧЫЛАР ҮРНӘК КҮРСӘТӘЛӘР

Чистайдагы судноларга ремонт ясау заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары социалистик ярыш буенча алган йөкләмәләрен үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. Заводның алдынгы стахановчылары үзләренең нормаларын ике-өч тапкыр арттырып үтиләр һәм ремонт эшләрен отлично сыйфат белән башкаралар.

Токарь цехы коллективы алдынгылык өчен большевистик көрәш алып бара. Бу цех айлык планны арттырып үти. Атаклы стахановчы иптәш Гибалин өч станокка хезмәт күрсәтеп, норманы 700 процент итеп үти. Токарьлардан Носков, Смирнов, Пепеляев иптәшләр хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечен бирәләр.

Казаннар цехы стахановчылары да калышмыйлар. Бу цехта коммунистлар алдынгы сафта баралар. Малыгин һәм Зуев иптәшләр норманы системалы рәвештә 170 процент итеп үтиләр. Алар үз тәҗрибәләрен башкаларга күчерәләр.

Ремонт эшләре төгәлләнгән судноларның саны артканнан-арта бара. „Красный Сормово“, „Серп“, „Ленинград“ һәм башка пароходларга ремонт үткәрү күптән төгәлләнде. Судноларның алдынгы кешеләре—командирлары, капитаннары һәм механиклары ремонтны вактында һәм югары сыйфатлы итеп төгәлләү өчен якыннан торып булышлык күрсәтәләр.

П. Кощеев.

ИРЕШЕЛГӘН УҢЫШЛАРНЫ НЫГЫТЫРГА

Аракчино затонында судноларга ремонт ясау темпының акырын баруы турында газетабызда байтак кына сигналлар булды. Бу сигналлардан соң затон җитәкчеләре кайбер практик чаралар күрделәр. Алар стахановчылык хәрәкәтенә оператив җитәкчелек итә башладылар. Моның нәтиҗәсе яхшы. Январь аенда затонда 34 стахановчы бар иде. Март аенда аларның саны 170 кешегә җитте. Стахановчылар мәктәбенең ролен аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Стахановчылар бу мәктәп аркылы үзләренең тәҗрибәләрен башкалар белән киң күләмдә урталашалар. Ике станокта эшләүче иптәш Медведев өйрәнчек Климинны III нче разряд токарь итеп хәзерләде. Хәзер иптәш Климин норманы 180 процент итеп үти. Котельщик мастер иптәш Аверянов ике кешене өйрәтте. Механик иптәш Маротканов өч слесарьны, маляр цехы мастеры иптәш Карсанов өч кешене, балта осталары бригадиры иптәш Чигарев өч кешене квалификацияле эшкә өйрәттеләр.

Алдынгы стахановчыларның якыннан торып булышлык итүләре нәтиҗәсендә 5 нче апрельгә 42 кеше стахановчылар мәктәбен тәмам итеп чыктылар.

Төрле профессияләрдә эшләүчеләрнең саны арта бара. Шкиперлардан 73 кеше үз судноларына хезмәт күрсәтү белән бергә, балта осталыгы һәм конопатлык эшләрен башкаралар. Шкипер ярдәмчесе иптәш Чинаев бу эштә аеруча үрнәк күрсәтте һәм шуның өчен дирекция тарафыннан бүләкләнде.

Судноларга ремонт ясауның сыйфатын тикшерү буенча җәмагат смотры үткәрелде. Бу смотр 21 суднога отлично һәм яхшы сыйфатлы ремонт ясалган дип тапты һәм эштә булган кайбер җитешсезлекләрне күрсәтте. Хәзер бу җитешсезлекләрне бетерү өчен практик чаралар күрелә.

Ф. Исхаков.

Татарстанга нәсел терлекләре китерү

Татарстанның терлекчелек фермаларына Советлар Союзының төрле өлкәләреннән нәселле терлекләр китерелә. Архангельски өлкәсеннән—Холмогор нәселле 300 үгез һәм 100 бозау китерелә. Ярославльдән—„Швиц“ нәселле 100 үгез. Чкалов өлкәсеннән—„Прекос“ нәселеннән 100 баш сарык, Сталинградтан — 300 „Прекос“ тәкәсе, 500 баш бәрән, Тамбов өлкәсеннән 300 баш ак дуңгыз китерелә.

ОПЕРА ТЕАТРЫ ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы опера театры төзелешенең барышы турындагы мәсьәләне тикшереп, конкрет чаралар билгеләгән иде. Ләкин Татстройтрест җитәкчеләре үз бурычларын үтәүгә әлегә кадәр ныклап керешкәннәре юк. 1940 нчы елның төзелеш эшләренә алдан хәзерлек чаралары тәэмин ителмәде. Төзү материаллары хәзерләү гадәттән тыш әкрен бара. „Строитель“ кирпеч комбинаты опера театры төзелешенә кирәк булган кирпечне бер генә айда да биреп җиткергәне юк.

1940 нчы елны тимер-бетон эшләре алып барылырга тиеш. Моның өчен иң беренче чиратта кирәк булган гравий хәзерләүне дә Татстройтрест җитәкчеләре шушы көнгә кадәр тулысынча хәл итмәделәр. Ә гравий хәзерләү үткән елның җәендә үк төгәлләнергә тиеш иде.

Татстройтрест управляющие иптәш Дивавинның әйтүенә караганда, фонд буенча бирелә торган материаллар хәзерләү эше беркадәр яхшы тора. Бу материалларны төзелеш мәйданында үз вактында файдалану өчен, югарыда әйткәнебезчә, гравий кирәк булачак. Безнең республикабызда гравий җитәрлек кадәр бар һәм аны алдан ук хәзерләп куярга мөмкин. Ләкин трест җитәкчеләре бу эшне үз вактында хәл итү өчен конкрет чаралар күрмиләр.

Төзелештә кадрлар хәзерләү эше һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, балта осталарыннан бары 8 кеше генә эшли. Барлыгы 51 кеше булырга тиеш. Башка профессияләр буенча да мәсьәлә әнә шулай тора.

Татарстан Совнаркомы опера театры төзелешенә күбрәк игтибар итәргә тиеш. Төзелештә финанс эшен тәртипкә саласы бар.

Төзү материалларына дөрес калькуляция билгеләү, ныклы чертежлар булдыру буенча да күп кенә җитешсезлекләр бар.

Татстройтрест опера театры төзелешен бөтен чаралар белән ашыктырырга, 1940 нчы елга билгеләнгән заданиене тулы үтәргә тиеш.

Егоров.

БЕРЕНЧЕ КВАРТАЛ ПЛАНЫ АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Татпромсовет системасындагы артельләрдә республикабызның XX еллыгына хәзерлек көннән-көн көчәя. Күп кенә артельләрнең коллективлары бу уңай белән алган йөкләмәләрне уңышлы үтиләр. Трикотажпромсоюзның „Коллективный труд“, „Ударница“, „Текстиль“, „Разнопромысловик“ артельләре 1940 нчы елның беренче квартал планын 20 нче мартта ук 103—119 процент итеп үтәделәр.

И. Кәрим.



Булдырь нефть разведкасында үзе яза торган контроль прибор эшли, шуның ярдәме белән бораулауның барлык эшләре теркәлеп барыла. Рәсемдә: өлкән инженер иптәш И. Г. Шеломанов 1 нче номерлы бораулау скважинасының эшен тикшерә. А. Костин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

БӘЙРӘМ ХӨРМӘТЕНӘ

Татшвейпромсоюз артельләрендә Татарстан АССР ның XX еллыгы хөрмәтенә социалистик ярыш киң җәелде.

Артельләр беренче квартал планын 113 процент үтәделәр. Арча районының „Кызыл Масра“ артеле „Заря“ артелен социалистик ярышка чакырган иде. „Заря“ артеле членнары аның чакыруын кабул иттеләр. Ярыш нәтиҗәсендә „Кызыл Масра“ артеле беренче квартал планын 13 нче февральгә, „Заря“ артеле 28 нче февральгә үтәделәр. „Швеймехпром“, „Конфексион“, „Швейник“ һәм „Азат Хатын“ артельләре дә планны срогыннан элек үтәделәр.

Татарстанның XX еллыгына „Швеймехпром“ һәм „Азат Хатын“ артельләренең мастерскойлары өстәмә рәвештә механикалаштырыла. Норлат районының „Красная Звезда“ артеле яңа төр продукция—калдык материалләрдән паласлар һәм дорожкалар җитештерүне үзләштерде.

ОЛИМПИАДА

Татарстан АССР ның XX еллыгына хәзерлек уңае белән шушы көннәрдә Азнакай районы үзәгендә үзешчәнлек сәнгате олимпиадасы үткәрелде. Олимпиадада музыкантлардан, җырчылардан, биючеләрдән 60 кеше, шулай ук ике колхозның агитколлективы катнашты. Алар ике көн эчендә үткәрелгән кичәләрдә 150 дән артык номер башкардылар. Гармонда уйнау буенча беренче урынны иптәш Ибраһимов, җыр буенча беренче урынны иптәш Хәсәнова, йорт хозяйкасы иптәш Лотфуллина икенче урынны алды. Декламация буенча иптәш Килмәкеев беренче урынны, биючеләрдән иптәш Хәйруллин беренче урынны, иптәш Яковлев икенче урынны алдылар. Бу иптәшләр республика олимпиадасында катнашу өчен кандидат итеп билгеләнделәр. Өстен чыккан 28 кеше 1.300 сум акча белән бүләкләнде.

Д. Зиннуров.

КОШЛАРНЫҢ КИЛҮЕ

Яз башлану белән җылы яклардан кошлар очып килә башладылар.

Казан Метеорология станциясеннән алынган мәглүматларга караганда, быел кара каргалар һәм тургайлар Татарстанга 27 нче мартта күпләп очып килгәннәр. Сыерчыклар 3 нче апрельдә килә башлаганнар.

1915 нче елда кара каргалар 31 нче мартта, 1920 нче елда 7 нче мартта килгән булганнар, 1907 нче елда сыерчыклар 15 нче апрельдә, 1914 нче елда тургайлар 17 нче мартта килгәннәр.

Шушы көннәрдә торналарның, кыр казларының һәм кыр үрдәкләренең дә килә башлаулары көтелә.

Казан Стоматология Институтында беренче чыгарыш

Быел Казан Стоматология институтында беренче тапкыр чыгарыш була. Институтны квалификацияле 58 врач-стоматолог тәмам итеп чыга. Алардан 5 кеше Кыргызстан ССР га эшкә барырга теләгәнлекләрен белдерделәр. Кайберләре Амур буендагы Комсомольски шәһәренә һәм Чкалов өлкәсенә баралар. 15 кеше Татарстан АССР да эшләргә кала. Удмуртия АССР га 6 кеше, Чувашстан АССР га 3 кеше бара. 11 кеше доцентлыкка һәм профессорлыкка хәзерләнү өчен институтта кала.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Казан шәһәре Бауман районы
МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ
1940 нчы елның җәйге сезоны өчен Бауман районы пионерлар лагерына путевкалар алырга теләгән оешмалар белән
ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ
БАШЛАДЫ
Казан, Миславский урамы, 8-1, Район Мәгариф бүлеге. 589—1

ДОК та (Казан, Триумфальный урам, 2)
ТӨРЛЕ ЗУРЛЫКТА
тәрәзә рамалары һәм ишекләр
— САТЫЛА —
583—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 8 нче апрельдә
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 8 нче апрельдә
МАСКАРАД
Иртәгә, 9 нчы апрельдә
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
9 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ИРЕК
10 нчы апрельдә
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9 - 30 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КАТЕРИНА
КУЛЬТУРА САРАЕ	Кече залда, 5, 7 һәм 9 да ГРОЗА. Зур залда, кич 10 да ҖИР ПЛЕНДӘ

КИРӘК:
Казан Эпидемиология һәм Микробиология институтына даими эшкә КАРТОТЕКАЧЫ, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАР һәм термос, шулай ук автоклав эшләрен белүче СЛЕСАРЬ. 575—3—2

АВТОКУЗОВНЫЙ ЗАВОДКА (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) БАШ МЕХАНИК, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР һәм 5—6 нчы РАЗРЯД КАЛАЙЧЫЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Заводның кадрлар бүлегенә килергә. 584—3—1

Чит илләрдә

Франциянең коммунист депутатларына хөкем карары чыгарылуга каршы протестлар

ЛОНДОН, 6 апрель. (ТАСС). Франция парламентының коммунист депутатларына карата Париж суды чыгарган хөкем карарыннан Англия хезмәт ияләренең ачулары Франция хөкүмәтенең коммунистик эш өчен үлем җәзасы бирүне күздә тота торган декрет проекты иглан ителгәннән соң тагын да көчәйде.

„Англиянең гражданлык ирекләрен саклаучы милли советы“ның кичә иглан ителгән белдерүендә: „Совет Рейно хөкүмәтенең яңа декреты Франция халкының хокукларын кысу дигән сүз дип саный“ диелә. Совет декретны юкка чыгаруны таләп итә.

„Дейли уоркер“ газетасы, Франция хөкүмәтенең яңа декреты Франциядәге чын хәлне һәм сугышка каршы, шулай ук эшчеләр арасындагы корбаннарга каршы эшчеләр сыйныфының протестын бастырырга маташучы Франция властьларының террорын ачык күрсәтә, дип яза.

Англиянең күп кенә эшчеләр оешмалары Франциянең коммунист депутатларына хөкем карары чыгарылуга каршы протест йөзеннән Франциянең Лондондагы илчелеге бинасы алдында демонстрация ясадылар.

НЬЮ-ЙОРК, 6 апрель. (ТАСС). „Дейли уоркер“ газетасы Франциянең коммунист депутатларына чыгарылган хөкем карарына каршы протест белдереп, аны „җинаять“ дип атый. Газета, коммунист депутатлар бөтен Франция халкы исеменнән сөйләп, какшамаслык героик позиция алдылар, дип яза.

„Дейли уоркер“ Америка профсоюзларын һәм башка прогрессив оешмаларны Франция властьларының бу хәрәкәтенә каршы протест белдерергә, коммунист депутатларны азат итүне һәм Франция халкына аның конституцион хокукларын кайтаруны таләп итәргә чакыра.

НЬЮ-ЙОРК, 6 апрель. (ТАСС). „Дейли уоркер“ газетасының Мексикадагы хәбәрчесенең язуына караганда, Мексика компартиясенең урыннардагы оешмаларының 600 җитәкчесе катнашкан җыелышта Франциянең коммунист депутатларына чыгарылган хөкем карарына каршы протест белдереп резолюция кабул ителгән. Резолюция реакциягә каршы көрәшне көчәйтергә чакыра.

„Мексика эшчеләре конференциясе“ һәм „Эль популяр“ газетасы да шулай ук Франциянең коммунист депутатларына хөкем карары чыгарылуга каршы протест белдерәләр.

Рейно хөкүмәтенең хәле

ПАРИЖ, 6 апрель. (ТАСС). Рейно хөкүмәтенең хәле әле һаман да ныклы түгел. Шушы көннәрдә радикал - социалистларның парламент группасының утырышы булды. Бу утырышта депутатлар палатасында хөкүмәтнең гомуми политикасы турындагы мәсьәлә буенча фикер алышулар башлауны таләп итү өчен Рейнога делегация җибәрергә карар бирелде. Рейно депутатлар палатасында фикер алышулар башларга үзенең ризалыгын белдерде. Ләкин шулай да монын хөкүмәтнең хәлен җиңеләйтмәгәнлеген әйтәләр, чөнки радикал - социалистлар группасы үзенең искәрмәләреннән һәм дәгваларыннан баш тартмаган әле. Шуның өстенә Рейно хөкүмәте „Республика федерациясе“ группасының каршылыгына очрый. Бу группа хөкүмәтнең персональ составыннан риза түгел. Рейно хөкүмәтенә яратмыйча карау парламентның „социалистлар һәм республикачылар союзы“ группасы депутатлары арасында да бар. Кайбер газеталар, ихтимал, 9 нчы апрельдә хөкүмәт аударып ташланыр дип язалар.

ПРИТТНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 6 апрель. (ТАСС). Глазгода атнага бер чыга торган „Форвард“ журналы Англиянең түбәнге палатасы члены, әле күптән түгел генә Советлар Союзының тынычлык политикасын яклаган өчен лейбористлар партиясеннән чыгарылган Приттның белдерүен басып чыгарды. Притт үзенең лейбористлар партиясеннән чыгарылу өчен сылтау була алырлык бер нәрсә дә эшләмәгәнлеген әйтә. „Лейбористлар партиясе башкарма комитетының мине партиядән чыгаруы өчен бердән-бер сәбәп булса, ул да минем ике китабым—„Москва турында дөреслек“ һәм „Сугыш киңәергә тиешме?“ дигән китапларым булды“. Притт хәзерге вакытта эшчеләр җыелышларында чыгуын үтенеп үзенә элеккегә караганда да ешрак мөраҗәгать итүләрен яза. Соныннан Притт болай ди: „Мин социализмны яклавымда һәм Советлар Союзына карата сугышка каршы чыгуымда дәвам итәчәкмен“.

ВУЛТОННЫҢ МӨРАҖӘГАТЕ

ЛОНДОН, 6 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, яңа билгеләнгән азык тәэминаты министре Вултон азык товарларына экономия ясау өчен киң кампания башлаган. Вултон „кухня фронты“ оештыру өчен тупланырга чакырып хатын-кызларга мөраҗәгать иткән. Мөраҗәгатьтә, азык кыенлыклары уңае белән „кухнягә керә торган барлык азыктан иң соң чиккә кадәр файдаланырга кирәк“ диелә.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Наньниннан көньяк-көнчыгыштарак Гуандун провинциясенең Цинчжоу-Синьсян районында сугышлар бара. Монда японнарның 6 меңләп гаскәре тупланган.

Шулай ук Сватоудан төньяк-көнчыгыштарак Чжаоань тирәләрендә дә зур сугышлар җәелеп бара.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Суйюань провинциясендә кытай гаскәрләре, чигенеп баручы японнарны эзәрлекләп, Уюаньнан төньяк-көнчыгыштарак ике стратегик пунктны алдылар. Кытай гаскәрләренең алгы частьләре Аньбэйгә якынлашып киләләр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Кытай гаскәрләре Чжэцзян провинциясендәге Сяошань районында японнарның позицияләренә һөҗүм итәләр.

Курчак „хөкүмәт“ нең Шанхай—Нанкин тимер юлын саклаучы 4 меңнән артык солдатлары Уси шәһәре якынында японнарга каршы баш күтәргәннәр һәм анда 3 нче апрельдә шәһәрнең японнар гарнизонына каршы сугышканнар.

⁂

3 нче апрельдә кытай бомбардировщикларының бер группасы Хунань провинциясендәге Иочжоуга һөҗүм ясаган. Японнарның бензин, сугыш кирәк-яраклары һәм азык саклана торган складларын ут чолгап алган. Кытайларның барлык самолетлары үз базаларына кайтканнар.

5 апрель. (ТАСС).

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1362. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1278.